**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«БОЛГАР ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 57-2 «8» сентябрь 2020 ел

Бюджет процессын оештыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының «Спас муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән Спас муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары арасында килешүләр төзү тәртибен раслау турында" 2019 елның 29 июлендәге 40-9 номерлы карары нигезендә Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советына вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле үзидарә органнарына бюджет процессын оештыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү һәм җирлекнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу өлешендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәре Башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрнең бер өлешен Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән тапшыру турында килешүләр төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны закон белән билгеләнгән вакытта Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районының
«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге
башлыгы вазыйфаларын башкаручы С.И. Тюнев

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ГОРОД БОЛГАР» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БОЛГАР»
ИНН 1637000411